ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Ленина, д.1а, ,
423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Димтамак авылы, Ленин урамы, 1а
йорт, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz @tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**19 гыйнвар 2021 ел** **№2**

**Дим-Тамак авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясенең бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында»гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Дим-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

2020 елның 12 ноябрендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Тарлау торак пунктында узган 2 санлы халык җыены карары,

2020 елның 13 ноябрендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Яссы-Тугай торак пунктында узган 3 санлы халык җыены карары,

2020 елның 14 ноябрендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Алабакүл торак пунктында узган 5 санлы халык җыены карары,

2020 елның 16 ноябрендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Дим-Тамак торак пунктында узган 6 санлы халык җыены карары,

2020 елның 23 ноябрендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Ак-Юл торак пунктында узган 7 санлы халык җыены карары,

2020 елның 26 ноябрендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Екатериновка торак пунктында узган 8 санлы халык җыены карарларын тормышка ашыру максатларында,

Дим-Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Дим-Тамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Дим-Тамак авыл җирлеге
башлыгы: Җ.Ә.Хөснетдинов

2021 елның 19 гыйнварындагы
Дим-тамак авыл җирлеге башкарма
комитетының
карарына 1 кушымта

**Дим-Тамак авыл җирлегендә**
**үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

1. Дим-Тамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен әлеге тәртип билгели.

2. Дим-Тамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар, тавыш бирүдә катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 25 мартына кадәр гражданнар, балачактан инвалидлардан, I һәм II төркем инвалидлардан тыш, Россия Федерациясе Коралллы Көчләре сафларына хезмәт итәргә чакырылган гражданнар тарафыннан үзара салым акчалары түләү башкарыла.

3. Билгеле сәбәпләр аркасында түли алмау түбәндәге очракларда карала:

а) яшәү урынында озак вакыт яшәмәү,

б) авыру булган  гражданнарга гариза язу нигезендә өч айга кадәр

кичектерү каралырга мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында белдерү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук имзаны тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерүдә (хәбәрнамәдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Дим-Тамак авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмаларына) Дим-Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша, гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

2021 елның 19 гыйнварындагы
Дим-Тамак авыл җирлеге
башкарма комитетының 2 санлы
карарына 2 кушымта

Дим-Тамак авыл җирлеге
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Түләүченең
Ф.И.А.___________________________________________________________________
Адресы: ___________________________________________________________________
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге ____________________торак пунктында узган халык җыены карары нигезендә,
2020 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча_____________________________вакытка кадәр җыен чараларын тормышка ашыру өчен елга бер тапкыр түләүне _____________________________________________ түбәндәге реквизитлар буенча түләүне тормышка ашырырга киңәш ителә:

Түләүне алучы банк ____________________________________________
БИК______________________________________________

Түләүне алучы___________________________________________________
Сч. №_____________________________________________________________
ИНН ______________________ КПП __________________________
КБК___________________________________
ОКТМО_______________________________________________
2021 ел өчен **гражданнарның үзара салым түләүен билгеләү.**

Җитәкче__________________ ____________________________________________
М.П. (имза) (имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү урыны** - - - - - - - - - - - - - - -

Дим-Тамак җирлеге бюджетына (муниципаль берәмлек исеме)
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турындагы_________________
*сумлык* __________________ *санлы* белдерү (хәбәрнамә)
Түләүченең
Ф.И.А.___________________________________________________________
Адресы:
___________________________________________________________________
Алдым: "____"___________________20___ел.
____________________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә: Әгәр белдерү (хәбәрнамә) түләүчегә шәхсән тапшырылса, өзеп алынган өземтә Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тутырыла һәм аларда кала (саклана).*